Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

15 ноябрь, 2021 ел № 4

Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Колай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 59 номерлы Колай авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Колай авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Арышхазда авылында. Халык җыенын ике этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2021 елның 28 ноябрендә 13.00 сәгатьтә Үзәк урамы, 15А йорт адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Үзәк, Колхоз урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2021 елның 28 ноябрендә 13.00 сәгатьтә Үзәк урамы, 15А йорт адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Елга арты, Чокыр арты, Бакча урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2022 елда Арышхазда торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын, көндезге уку формасы студентларын, 80 яшькә җиткән гражданнарны,бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү;

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Тогашево авылында. 2021 елның 28 ноябрендә 12.00 сәгатьтә Космонавтлар урамы, 51А йорты буенча урнашкан кибет янында халык җыенын үткәрергә:

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2022 елда Тогашево торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, 1 төркем инвалидларны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.3. Карповка бистәсендә. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын ике этапта үткәрергә:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2021 елның 28 ноябрендә 16.00 сәгатьтә Совет урамы, 37А йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Совет урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2021 елның 28 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Совет урамы, 37А йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Урман, Күл урамы йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2022 елда Карповка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларны, көндезге уку формасы студентларын, 80 яшькә җиткән гражданнарны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.4. Олы Дүртөйле авылында. 2021 елның 4 декабрендә 10.00 сәгатьтә Кооператив урамы, 2А йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында гражданнар җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2022 елда Олы Дүртөйле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарны, 80 яшькә җиткән гражданнарны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.5. Колай авылында. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын сигез этапта үткәрергә:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2021 елның 4 декабрендә 11.30 сәгатьтә Яшьләр урамы, 26Б йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Яшьләр урамының 26-105 йортлары, Юл урамының 1 номерлы йорты буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2021 елның 4 декабрендә 12.00 сәгатьтә Яшьләр урамы, 26Б йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Яшьләр урамының 4-25 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының өченче этабы 2021 елның 4 декабрендә 14.00 сәгатьтә Яшьләр урамы, 26Б йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Яшьләр урамының 1-3 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының дүртенче этабы 2021 елның 11 декабрендә 10.00 сәгатьтә Совет ур., 34 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Совет урамының 1-47 йортлары, Совет урамының 1-47 йортлары, Яшел урамының 1-12 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының бишенче этабы 2021 елның 11 декабрендә 11.30 сәгатьтә Чкалов урамы, 7 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Чкалов урамының 2-28 йортлары, Профсоюз урамының 1-29 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

- гражданнар җыенының алтынчы этабы 2021 елның 11 декабрендә 13.00 сәгатьтә Чкалов урамы, 1А йорты буенча урнашкан авыл мәдәният йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Тау асты урамының 1-23 йортлары, Полужная урамының 1-29 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

- гражданнар җыенының җиденче этабы 2021 елның 11 декабрендә 14.30 сәгатьтә Профсоюз урамы, 33 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Профсоюз урамының 32-34 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

- гражданнар җыенының сигезенче этабы 2021 елның 11 декабрендә 15.30 сәгатьтә Профсоюз урамы, 36 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Профсоюз урамының 35-37 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2022 елда Колай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, көндезге уку формасы студентларын һәм мәктәп укучыларын, Чернобыль АЭС нең калдыкларын бетерүдә катнашучыларны, 80 яшькә җиткән гражданнарны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Колай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге башлыгы Н.В. Поповская